ГЛАВА ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.09.2019 г. Заинск №166

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башлыгының 2007 елның 26 февралендәге 13 номерлы "Зәй муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалауның күп баскычлы системасын төзү турында" карарының үз көчен югалтуын тану хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре» турында 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законы, 2017 елның 11 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» Татарстан Республикасы законы белән, Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башлыгының 2007 елның 26 февралендәге 13 номерлы «Зәй муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалауның күп баскычлы системасын төзү турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башлыгының 2015 елның 2 июлендәге 30 номерлы, 2015 елның 2 октябрендәге 60 номерлы, 2018 елның 30 маендагы 133 номерлы, 2019 елның 3 апрелендәге 82 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән).
2. Әлеге карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
3. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башлыгы урынбасары В.Г. Акатьевка йөкләргә.

**Зәй муниципаль районы башлыгы** **Р.Г. Кәримов**

Кудряшов В.В.
7-10-27